**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**2 ноябрь 2023 ел** **№2**

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пункты территориясендә беренче теркем инвалидлардан, Беек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән гаиләләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт тезегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Халыкны су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм тоту, килешү буенча эш өчен түләү, материаллар, җиһазлар, материаллар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту (Верхняя, Средняя, Нижняя урамнары буенча вак ташлар салу, тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр ечен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре ечен түләү, килешү буенча эшләр ечен түләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урманай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге башлыгы Э.Р.Абдуллина